КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 май г.Казань № 337

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары кабул ителгәндә һәм гамәлгә ашырылганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары кабул ителгәндә һәм гамәлгә ашырылганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары кабул ителгәндә һәм гамәлгә ашырылганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 февраль, 87 нче; 2019 ел, 15 май, 392 нче; 2023 ел, 15 апрель, 469 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары кабул ителгәндә һәм гамәлгә ашырылганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турындагы

нигезләмәгә, 1.3 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Социологик тикшеренүләрдә катнашкан респондентларның 50 процентыннан артыгы билгеләгән гавами өстенлекләр реестры – актуаль гавами өстенлекләр исемлеге.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин